РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41


---

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 50 2021 елның 1 сентябре

## Түбән Кама муниципаль район Советының 2019 елның 25 июлендәге 48 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре исемлегенә өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының 2019 елның 25 июлендәге 48 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре исемлегенә әлеге карарга кушымта нигезендә редакциядә юллар өстәргә.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль район
Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
50 номерлы карарына
кушымта

Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре исемлеге

| ОКВЭД коды | Эшчәнлек төре исеме |
| --- | --- |
| 55 | Вакытлыча яшәү өчен урыннар бирү буенча эшчәнлек |

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.В.Умников